ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» февраль 2021 ел № 39

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның 11 сентябрендәге
297 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет
учреждениесенең яңа штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 сентябрендәге 297 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 15 февралендәге 84 номерлы үтенечнамәсен карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының «Федераль законнарны бозуларны бетерү турында» 2021 елның 26 гыйнварындагы 02-08-02/31 номерлы күрсәтмәсен үтәү өчен, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 сентябрендәге 297 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Директор урынбасары» сүзләрен «Спорт җиһазларын (спорт корылмасын, спорт объектын) эксплуатацияләү буенча директор урынбасары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга..

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**